Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең
Югары Мактама торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы карары

15 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның «11» ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2021 елның «11» ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның «12» ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2021 елның «12» ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Сез 2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме: юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү”.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 768 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 431 кеше, бу 51,7% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 397 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 34 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Т.Нуриев